**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2025 Балык Бистәсе штп №320пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» 05.05.2023 №141пи карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кулланучыларның үзләренең өстәмә ихтыяҗларын канәгатьләндерү хокукын гамәлгә ашыру, кулланучыларга күрсәтелә торган хезмәтләр ассортиментын киңәйтү, булганнарыннан файдалану мөмкинлекләрен арттыру һәм өстәмә ресурс потенциалын җәлеп итү, китапханә хезмәте күрсәтүнең уңайлылыгын арттыру һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында китапханә фондларын саклау буенча эш алымнарын көчәйтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктчасы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 9.2 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» 05.05.2023 №141пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Балык Бистәсе муниципаль районының «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең «Пушкин картасы» проекты буенча түләүле хезмәтләргә бәяләр прейскурантын кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль район
Башкарма комитеты
24.12.2025 № 320пи
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының
“Үзәкләштерелгән китапханә системасы” МБУ түләүле хезмәт күрсәтүләргә
БӘЯЛӘР ПРЕЙСКУРАНТЫ

| Хезмәтләр атамасы | Бәясе сумнарда |
|---|---|
| «Пушкин картасы " буенча чаралар | |
| Мастер-класслар | 250 сум. (бәя килешү буенча) |
| Чараларны яңа форматларда үткәрү:<br>- тренинг дәресләре<br>- квестлар<br>- арт-уеннар<br>- танып белү<br>- шигъри вернисажлар<br>-этноочрашу<br>- фольклор утырмалары (уен программасы)<br>- шигъри кәеф кичәсе<br>-әдәби сәяхәт<br>-бал<br>- брейн-ринг | 200 сум. |
| Китапларны тәкъдир итү | 200 сум. |
| Әдәби-музыкаль кичәләр | 200 сум. |